| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.04.2019 № 541

2019 нчы елдаАлабуга муниципаль
районы гомуми белем бирү
учреждениеләрендә укучыларны кайнар аш
белән тәэмин итүне оештыру турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законы, «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында»гы 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында социаль стандартлар һәм социаль натураль нормалар турында»гы 1996 елның 9 декабрендәге 1022 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, 2.4.5.2409-08 "Татарстан Республикасында гомуми белем бирү учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укучылар туклануын оештыруга санитария-эпидемиология таләпләре"нә, Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы гомуми белем бирү учреждениеләрен норматив буенча финанслауны кертү турында» гы 2017 ел, 8 август, 566 нчы карары, шулай ук балаларны социаль яклау, сәламәтлекләрен ныгыту максатыннан, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф учреждениеләрендә укучыларны балансль кайнар аш белән тукландыру нормаларын үтәүне тәэмин итү таләпләре нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә:

1. Алабуга муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә балаларны кайнар аш белән тәэмин итү турындагы нигезләмәне расларга.
2. Гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем алучы 1 укучы өчен көненә 34 сум 20 тиен (7 сум 40 тиен район бюджетыннан, аерманы ата-аналар хисабыннан) итеп билгеләргә.
3. Гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем алучы 1 укучы өчен түләүсез кайнар ашның бәясен көненә 7 сум 40 тиен хисабыннан билгеләргә.
4. Түбәндәге укучыларны түләүсез кайнар аш белән тәэмин итәргә:
-4 һәм аннан күбрәк балигъ булмаган балалы гаиләдә тәрбияләнүчеләрне;
- бер кешегә уртача керем яшәү минимумыннан түбән булган гаилә балаларын.
Гаиләнең яшәү минимумы Муниципаль казна учреждениесе ”Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы мәгариф идарәсе һәм ДКУ “Республика материаль ярдәм күрсәтү үзәге” ведомостара teләктәшлек нигезендә билгеләнә.
- туберкулездан дәваланучы балалар;
- дәүләт учреждениеләрендә тулы дәүләт тәэминлегендә торучы балалар;

- бишкөнлек хәрби җыен вакытында 10 сыйныф яшүсмерләре.
5. 2019 нчы елда кайнар аш белән туклануның компенсация күләмен җирле бюджет хисабыннан 1 укучы өчен көненә 7 сум 40 тиеннән билгеләргә.
6. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы финанс-бюджет палатасына (Садыкова Э.И.) муниципаль заданиене финанслау кысаларында укучыларны кайнар аш белән тәэмин итүне бюджет мөмкинлегеннән чыгып билгеләүне тәкъдим итәргә.
7. МКУ "Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф идарәсе" башлыгына (Р.И.Зарипов):
7.1. Витамин, микроэлементлар белән тулыландырылган туклануның нормасын, сыйфатын исәпкә һәм контрольгә алырга.
7.2. Сыйфатлы туклануны оештыру өчен бүленгән акчаларның максатчан тотылуын тәэмин итәргә; мәктәп яны участокларында җитештерелгән продукция хисабына менюны тулыландыру буенча эшне көчәйтергә.
7.3. Гомуми белем бирү учреждениеләрен тоткарлыксыз туклану ризыклары белән тәэмин итүне оештырырга һәм контрольгә алырга.
7.4. Әлеге карарда күрсәтелгән гражданнарга социаль ярдәм чаралары турындагы мәгълүматны социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасын (ЕГИССО) файдаланып, ЕГИССО операторы тарафыннан билгеләнгән форматта җиткерүне тәэмин итәргә.
8. Алабуга муниципаль районы Республика материаль ярдәм күрсәтү үзәгенең 19 номерлы бүлегенә социаль ярдәм алучылар турындагы мәгълуматны"Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф идарәсе" муниципаль казна учреждениесе һәм ДКУ "Республика материаль ярдәм күрсәтү үзәге" ведомостарамәгълүмати хезмәттәшлек килешүе нигезендә тәкъдим итәргә.
9. Алабуга муниципаль районы гомуми белем оешмалары җитәкчеләренә:
9.1. Азык- төлек продуктлары белән тәэмин итүчеләрне билгеләү буенча килешүләр төзү һәм сату үткәрү өчен документларны үз вакытында тапшырырга;
9.2. Тәэмин ителә торган азык-төлек продуктларының сыйфатын контрольдә тотарга.
10. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районының 2018-2019 уку елына муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны туклandыру белән тәэмин итү турында" гы 2018 елның 23 ноябрендәге 1682 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.
11. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.
12. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Рыбакова Л. Н. йөкләргә.

Җитәкче Р.С.Хәйруллин